ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.10.2022 с. Русское Макулово 03

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Сеитово авылы гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 18 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Сеитово авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Сеитово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юллауга ризалыгыгыз бармы:

- Сеитово авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Сеитово ав., Үзәк ур., 6 йорт адресы буенча, 10.00 сәг. кибет бинасында халык җыенын үткәрергә

4. Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге башлыгы урынбасары П.Е. Карпухин